| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| ЧЕРЕМШАНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН | ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ |
| **СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115


**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Ульяновка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**15 декабрь 2025 ел** **№ 10**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру

нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 76 номерлы карарына (җирлек Советының 2018 елның 28 августындагы № 89, 2018 елның 15 ноябрендәге № 93, 2020 елның 23 октябрендәге № 8, 2022 елның 17 ноябрендәге № 78, 2023 елның 31 гыйнварындагы № 85, 2024 елның 20 июнендәге № 120, 2024 елның 27 декабрендәге № 142, 2025 елның 16 маендагы № 149 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Ивашкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 16928,0 сум тәшкил итә»;

1.2. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 3 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе                                                    Шәмсетдинов С.З.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Советының
2025 елның 15 декабрендәге
№ 10 карарына
кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 23201,0 |